| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 641-142/тэ-2025

«ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәрендә җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатыннан җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 ел, №662-91/тэ-2023 карары белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 ел, №662-91/тэ-2023 карарына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2025 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2026 елга җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмалары сатып ала торган җылылык энергиясенә тарифларны төзәтү максатларында һәм 2026 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп һәм озак сроклы җайга салу параметрын яңадан карап, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәрендә җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатыннан җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәрендә җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатыннан җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2023 ел, №662-91/тэ-2023 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2024 ел, №664-110/тэ-2024 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертеп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төзәтелгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәрендә җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатыннан җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2023 ел, №662-91/тэ-2023 карарына 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп, аңа үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 ел, № 662-91/тэ-2023
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 641-142/тэ-2025
карары редакциясендә)

# «ТГК-16» АҖ тарафыннан Казан шәһәрендә җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукциялэнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 899,60 | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр | 1 027,19 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 027,19 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 1 223,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 1 223,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 1 345,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 1 126,79 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 020,32 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 1 020,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 1 241,01 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 ел, № 662-91/тэ-2023
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 641-142/тэ-2025
карары редакциясендә)

## Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2024-2028 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ягулык чыгымнарын үзгәртү динамикасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | Билгеләнгән куәтнең 1 Гкал/сәгатенә җылылык энергиясе чыганакларында технологик бозылулар нәтиҗәсендә җылылык энергиясен бирүне туктату саны | Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан җибәрелә торган җылылык энергиясе берәмлеген җитештерүгә чыгымның чагыштырма чыгымы, кг/Гкал | |
| | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1 | Чыганак – «ТГК-16» АҖ филиалы – | 2024 | 390 965,21 | X | X | 0 | X | X |
| | | 2025 | X | 1 | X | 0 | X | X |

| Т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ягулык чыгымнарын үзгәртү динамикасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | Билгеләнгән куәтнең 1 Гкал/сәгатенә җылылык энергиясе чыганакларында технологик бозылулар нәтиҗәсендә җылылык энергиясен бирүне туктату саны | Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан җибәрелә торган җылылык энергиясе берәмлеген җитештерүгә чыгымның чагыштырма чыгымы, кг/Гкал | |
| | Казан ҖЭҮ-3 | 2026 | 437 381,16 <*> | 1 | Х | 0 | Х | Х |
| | | 2027 | Х | 1 | Х | 0 | Х | Х |
| | | 2028 | Х | 1 | Х | 0 | Х | Х |

<*> Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү нигезләренең 51 пункты нигезендә яңадан каралган

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге